# Муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында килешү

**Аксубай ш.т.п.** **«01» июнь2025 ел**

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставы нигезендәэшитүче, алга таба «Район башлыгы» дип аталучы Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башлыгы вазифасын вакытлыча башкаручы Заһидуллин Илшат Минсабирович, бер яктан, һәм икенче яктан Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Уставы нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгы Шакиров Ильнур Рәшид улы, алга таба «Җирлек башлыгы», «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (алга таба - 14-ТРЗ номерлы Закон), «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, (алга таба - 92-ТРЗ номерлы Закон) гамәлгә ашыру максатларында бергә «Яклар» дип аталып түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

## 1.Килешү Предметы

Килешүнең предметы булып 92-ТРЗ номерлы Законны гамәлгә ашыру максатларында муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында 14 - ТРЗ номерлы Законның 5 статьясында билгеләнгән белешмәләрне (алга таба шулай ук - документлар) җыю һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукыйактлары Регистрына (алга таба шулай ук-регистр) җибәрү мәсьәләләре буенча район башлыгы белән җирлек башлыгының үзара хезмәттәшлеген оештыру тора.

## 1. Якларнын хокуклары һэм бурычлары

Район башлыгы җирлек башлыгыннан документлар кабул итүне һәм аларны регистрга 14-ТРЗ номерлы законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда җибәрүне тәэмин итә. Җирлек башлыгы тәэмин итә: документларны 14-ТРЗ номерлы законда билгеләнгән нормалар һәм таләпләр нигезендә рәсмиләштерү; регистрга кертү өчен җибәрелә торган документларның тулылыгы һәм 14-ТРЗ номерлы законда билгеләнгән белешмәләрнең дөреслеге;

район башлыгы карары белән расланган Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турындагы белешмәләрне җыю һәм җибәрү буенча үзара хезмәттәшлек регламенты нигезендә билгеләнгән җирле үзидарә органына (вазыйфаи затына) документларны тапшыру 2015 елның 30.12 № 52.

## 2. Килешеунен гамэлдэ булу срогы

Әлеге килешү билгесез вакытка төзелде.

## 4. Килешүне туктату нигезләре һәм тәртибе

Әлеге Килешү вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:
якларның килешүе буенча;
якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән
очракта.

## 5. Якларнын жаваплылыгы

Якларның килешү шартларын үтәмәве яисә тиешенчә үтәмәве килешүне берьяклы өзү өчен нигез булып тора.

## 6. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр якларның үзара ризалыгы белән кертелә һәм язма рәвештә өстәмә килешү белән рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

6.2. Килешү тигез юридик көчкә ия ике нөсхәдә, һәр як өчен берәр нөсхәдә төзелде.

## 7. Якларнын имзалары

| | |
|---|---|
| Вакытлыча Татарстан Республикасы<br>Аксубай муниципаль районы<br>вазифаларын башкаручы | Татарстан Республикасы<br>Аксубай муниципаль районы<br>Яңа Кармәт авыл жирлеге башлыгы |
| ______________ И.М.Загидуллин | ______________ И.Р.Шакиров |